КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 30 декабрь г.Казань № 1259

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән агросәнәгать комплексын кадрлар белән тәэмин итүгә дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2017 ел, 21 декабрь, 893 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексын кадрлар белән тәэмин итүгә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан акча бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән агросәнәгать комплексын кадрлар белән тәэмин итүгә дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2017 ел, 21 декабрь, 893 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 26 март, 173 нче; 2019 ел, 6 сентябрь, 789 нчы; 2020 ел, 10 март, 181 нче; 2020 ел, 14 май, 389 нчы; 2020 ел, 30 декабрь, 1247 нче; 2021 ел, 16 июль, 580 нче; 2023 ел, 14 февраль, 145 нче; 2023 ел, 29 март, 372 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексын кадрлар белән тәэмин итүгә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан акча бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гариза бирү датасына яшь белгечнең яше 35 яшьтән артмый.»;

4 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бер тапкыр бирелә торган 750,0 мең сум күләмендә түләү – югары белемле һәм (яисә) урта һөнәри белемле белгечләр өчен. Яшь белгечләргә бер тапкыр бирелә торган түләү бер тапкыр бирелә.»;

өченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

дүртенче абзацта «бер тапкыр һәм ай саен бирелә торган түләүләрне (алга таба – түләүләр)» сүзләрен «бер тапкыр бирелә торган түләүне (алга таба – түләү)» сүзләренә алмаштырырга, «бер тапкыр һәм ай саен бирелә торган түләүләр» сүзләрен «бер тапкыр бирелә торган түләүләр» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Түләүләрне алу өчен яшь белгеч (алга таба – гариза бирүче), эшкә урнашканнан соң, әмма югары белем һәм (яисә) урта һөнәри белем алу турында документ бирелгән датадан алып өч елдан да соңга калмыйча, Идарәгә түбәндәге документларны тапшыра:»;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлык тарафыннан расланган форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Түләүләр алу өчен Идарәгә тапшырыла торган документларның күчермәләре авыл хуҗалыгы оешмасы һәм (яисә) кулланучылар кооперациясе оешмасы тарафыннан таныклана.»;

$7^{1}$ пунктның икенче абзацында «әлеге Тәртипнең $7^{1}$ пункты» сүзләрен «әлеге пунктның беренче абзацы» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктның икенче абзацында «2,0 мең сум» сүзләрен «5,0 мең сум» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктның икенче абзацында «1,0 мең сум күләмендә 50 стипендия» сүзләрен «3,0 мең сум күләмендә 115 стипендия» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктның беренче абзацында «1,0 мең сум» сүзләрен «3,0 мең сум» сүзләренә алмаштырырга;

12 пунктның беренче абзацында «30 яше» сүзләрен «35 яше» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин